КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 21 май г.Казань № 722

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 27 май, 355 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары арасында бүленә торган, Хисап чорына Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге мониторингы нәтиҗәләре һәм өч еллык чорга аларның планлаштырылган мәгънәләре турында Татарстан Республикасы җыелма докладына кертелә торган хисап чорына Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен каралган күрсәткечләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хисап елы өчен Татарстан Республикасы шәһәр округларының һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә мониторинг йомгаклары һәм өчьеллык чорга аларның планлаштырыла торган күрсәткечләре турында Татарстан Республикасы җыелма докладын әзерләү хакында» 2013 ел, 27 май, 355 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 24 февраль, 109 нчы, 2017 ел, 31 май, 326 нчы, 2018 ел, 1 декабрь, 1074 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары арасында бүленә торган, Хисап чорына

Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге мониторингы нәтиҗәләре һәм өч еллык чорга аларның планлаштырылган мәгънәләре турында Татарстан Республикасы җыелма докладына кертелә торган хисап чорына Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен каралган күрсәткечләр исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

26 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

261 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

36 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин